УДК 811.512.145’367

*Л.Г. Хәбибуллина*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ ТӨРЛӘРЕ

В статье изучаются спаянные предложения в татарском языке, которые являются специфической особенностью синтаксической системы тюркских языков. Они подчиняются главному предложению при помощи формы своего сказуемого (падежных аффиксов, формы условного наклонения, формы деепричастий, послелогов и послеложных слов). В академической «Татарской грамматике» (1995) М.З. Закиев впервые в татарском языкознании употребил термин «спаянные предложения» для обозначения таких предложений. Тем не менее в лингвистической литературе подобные конструкции по традиции называются синтетическими предложениями. В данной статье также освещается вопрос их рассмотрения в других тюркских языках, уделяется внимание и суперспаянным предложениям.

**Ключевые слова:** спаянные предложения, подчинительная связь, тюркские языки, татарский язык.

The article studies subordinate clauses in the Tatar language, which are a specific feature of the syntactic system of Turkic languages. They are subordinated to the main clause using the form of their predicate (case affixes, the form of the conditional mood, the form of gerunds, postpositions and postpositional words). In the academic “Tatar Grammar” (1995) M.Z. Zakiev for the first time in Tatar linguistics calls such sentences welded. Nevertheless, in the linguistic literature such constructions are traditionally called synthetic sentences. This article also covers the issue of their consideration in other Turkic languages and pays attention to super-cohesive sentences.

**Keywords:** subordinate clauses, subordinating connection, Turkic languages, Tatar language.

Иярткүче чаралар ияртүче җөмләнең хәбәре составында килгән синтетик бәйләүче чаралар булу төрки телләр, шул исәптән татар теле синтаксик структурасының специфик үзенчәлеген тәшкил итә. Мондый җөмләләр иярчен кисәкләргә охшаган була, араларында пауза булмау һәм баш җөмләнең аныклана торган сүзе белән мәҗбүри препозицион янәшә торулары сәбәпле аларны кушма җөмлә структурасыннан аерып алу авырлаша.

Төрки тел белемендә иярчен җөмлә төрләрен классификацияләү һәрвакыт бәхәсле. Кайбер телчеләр, гомумән, төрки телләрдә иярченле кушма җөмлә булуны кире кага [5]. Бу, кагыйдә буларак, синтетик иярченле кушма җөмләгә кагыла. Ә төрки телләрнең синтаксик системасында аналитик бәйләүче чаралы иярченле кушма җөмлә булу тюркологларда (М.З. Зәкиев, Н.З. Гаджиева, Л.А. Покровская, А.А. Юлдашев һ. б.) шик тудырмый. Татар телендә аналитик конструкцияләр С.М. Ибраһимов тарафыннан җентекле өйрәнелгән.

Мәгълүм булганча, 1982 елда лингвист В.Г. Адмони синтетик җөмләләрне *спаянный* дип атарга тәкъдим итә [1: 36]. Галимнең бу фикерен дәвам итеп, академик М.З. Зәкиев төрки телләрдә иярченле кушма җөмлә дип аналитик кушма җөмләләрне генә, ә синтетик кушма җөмләләрне ябешкәкле яки берекмәле кушма җөмлә дип атауны хуп күрә [8: 411–412].

Шул рәвешле, М.З. Зәкиев В.Г. Адмони тәкъдим иткән кушма җөмлә парадигмасын төрки телләр өчен кулай дип саный: паратаксис (тезмә кушма җөмлә), гипотаксис (иярченле кушма җөмлә), гипертаксис (*сложноспаянное предложение*) [7: 29].

Төрки телләрдә гипертаксиска караган җөмләләр (*сложноспаянное предложение*), кагыйдә буларак, иярченле кушма җөмлә составында карала, мәсәлән башкорт [17], казах [16], кыргыз [12], чуваш [11] һ. б. телләрдә. А.М. Саидов мондый төр җөмләләрне комык теле материалында анализлый. Галим билгеләгәнчә, комык тел белемендә мондый конструкцияләр иярченле кушма җөмлә яки гади җөмлә буларак өйрәнелә. Әмма «алар кушма һәм гади җөмләләр арасындагы позициядә тора, *«сложноспаянный»* дигән термин грамматик яктан әлеге конструкцияләрнең асылын төгәлрәк чагылдыра» [15: 17].

Кайбер төрки телләрдә, мәсәлән кыргыз телендә, иярченле кушма җөмлә компонентлары арасында өч бәйләнеш төре аерыла: аналитик, синтетик, синтетик-аналитик [13: 13].

Н.Н. Ефремов якут телендә иярченле кушма җөмләләрне өйрәнеп, аларның синтетик, аналитик-синтетик, аналитик типлары булуны ассызыклый [6].

Татар телендә дә иярченле кушма җөмлә компонентлары арасында бер үк вакытта синтетик бәйләүче чара да, аналитик бәйләүче чара да кулланыла ала. Шарт фигыль формасы белән бергә *әгәр* теркәгече килү аеруча еш очрый. Мәсәлән: *Әгәр ир акыллы булса, хатын күндәм була* (Мәкаль). Әмма синтетик чара белән аналитик чараның параллель кулланылуы стилистик төсмер функциясен генә үти. Әйтик, бу очракта *әгәр* теркәгечен төшереп калдыру җөмлә структурасын бозмый, димәк, шарт фигыль кушымчасы (синтетик чара) – төп бәйләүче чара, җөмлә синтетик була. Шуңа күрә татар телендә синтетик-аналитик (аналитик-синтетик) җөмлә дип аерып каралмый.

Аналитик иярченле кушма җөмләләрдә бәйләүче чара хәбәр формасына кагылмый, чөнки хәбәрдән тыш урнаша. Ә *спаянный* дип аталган җөмләләрне баш җөмләгә бәйләү өчен, иярчен кисәкләрне бәйләүче шул ук чаралар кулланыла, әлеге үзенчәлек аларны җөмләнең иярчен кисәкләре белән якынайта, мондый җөмләләр кушма җөмләне тәмамлап килә алмый. Аларны баш җөмләгә ияртү өчен хәбәр составына кергән һәм аның формасын тәшкил итә торган аффикслар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору (бу очракта хәбәр формасы белән берлектә) кулланыла. Мәсәлән:

– шарт фигыль формасы: *Кышын кар сора**саң**, кар да бирмәс* (Әйтем); *Авыр**саң**, имче күбәер* (Мәкаль);

– хәл фигыль формалары: *Җәйнең матур кояшлы көннәре бе**теп**, бөтен дөньяны болыт вә караңгылык каплады* (Г. Ибраһимов. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»); *Сугыш бет**кәч**, батыр күбәя* (Мәкаль); *Бер аягын атла**ганчы**, икенчесен эт ашый* (Әйтем); *Атың чык**канчы**, җаның чыксын* (Мәкаль);

– килеш кушымчалары, кайбер башка сүз бәйләүче кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр: *Ояты бар**ның** намусы бар; Ат эшләгәнг**ә**, эт әлсери; Малың бар**да** бар да дус; Ике карчыга талаш**канда,** бер мендәрлек йон чыга* (Мәкаль); *Ир кичмәс**лек** елга юк* (Мәкаль);

– мәҗбүри янәшә тору һәм ияртүче сүздән пауза белән аерылмау. Мондый конструкцияләр баш җөмләдәге кайсыдыр бер сүзнең атрибуты позициясендә була. Аларның хәбәрләре сыйфат фигыль, *бар, юк* хәбәрлек сүзләре, кайбер рәвешләр һәм сыйфатлар белән билгеләнә. Мәсәлән: *Артында йөз эт һауламаган бүре бүре буламыни?* (Мәкаль).

XX гасыр башы татар грамматикаларында ук, әйтик, Г. Ибраһимовның «Татар нәхүе»ндә (1919) иярчен җөмлә һәм ияртүле җөмлә аерыла.

Тел галимнәре Җ. Вәлиди «Татар теленең грамматикасы» (1919) хезмәтендә һәм Г. Алпаров «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) монографиясендә *сложноспаянный* җөмләгә туры килгән җөмләне – ияртүле (соңрак – иярченле) кушма җөмлә, ә иярченле кушма җөмләне бәйләүле кушма җөмлә дип атыйлар.

Әмма татар тел белемендә һәр ике төр җөмләне дә иярчен дип атау традициягә кергән: синтетик иярченле кушма җөмлә һәм аналитик иярченле кушма җөмлә.

1983 елда «Советская тюркология» журналында М. З. Зәкиев иярченле кушма җөмләне – тагылмалы кушма (иярчен җөмләне – тагылма җөмлә), *сложноспаянный* җөмлә – иярченле кушма (*спаянное* – иярчен җөмлә), дип атарга тәкъдим итә [7: 36].

Әмма әлеге төшенчәләр татар теленең лингвистик терминологиясенә кермәгән, гомумән, *сложноспаянное предложение* һәм *спаянное предложение* терминнарының татар теленә төгәл һәм гомум кабул ителгән тәрҗемәсе юк.

Мәсәлән, «Лингвистик терминнарның русча-татарча аңлатмалы сүзлеге»ндә *сложноспаянные предложения* термины синтетик кушма җөмләләр дип тәрҗемә ителә [14: 164], ә *спаянное предложение* атамасы берекмә җөмлә дип бирелә [14: 172].

Рус телендәге «Татар грамматикасы» (III том, Синтаксис, 1995) белән аның татар телендәге соңгы яңа басмасында (III том, Синтаксис, 2017) кушма җөмлә бирелешендә бик зур аермалыклар бар.

Рус телендә басылган академик «Татар грамматикасы»нда (III т., Синтаксис, 1995) *сложноспаянные предложения* дип аерып чыгарыла, «мондый җөмләләрдә ияртүле мөнәсәбәт ияреп килгән

җөмләнең хәбәре формасын тәшкил итүче чаралар ярдәмендә белдерелә» [8: 418]. Академик М.З. Зәкиев билгеләгәнчә, *спаянный* сүзе урынына *синтетик* сүзен кулланып була, ул башка шундый типтагы *синтетик чаралар, синтетик бәйләнеш* кебек терминнар ясау өчен кулайрак та [8: 424–425].

«Татар грамматикасы»ның татар телендәге яңа басмасында (III т., Синтаксис, 2017) иярченле кушма җөмләләр синтетик һәм аналитик төрләргә бүленә, дип бирелә. М.З. Зәкиев билгеләгәнчә, рус телендәге «Татар грамматикасы»нда *спаянное предложение* дип аталган синтетик иярчен җөмлә *ябешкәк* яки *берекмә җөмлә* дип тәрҗемә ителергә тиеш иде. Әмма татар тел белемендә мондый термин һәм кушма җөмләне болай төркемләү кабул ителмәгән. Шулай итеп, М.З. Зәкиев, бер яктан, әлеге җөмләләрнең синтетик иярчен җөмлә булуын кире какмый [18: 339].

Л.К. Бәйрәмова һәм Ф.С. Сафиуллинаның «Рус һәм татар телләренең чагыштырма синтаксисы» («Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков», 1989) хезмәтендә В.Г. Адмониның синтетик конструкцияләргә карата фикерләре, аларның атамасын үзгәртү тәкъдиме турында языла. Әлеге тәкъдимгә М.З. Зәкиевнең карашы яктыртыла. Әмма хезмәт авторларының бу мәсьәләгә карата үз позициясе, комментарийлары бирелми [3: 139–140].

Әлеге «Рус һәм татар телләренең чагыштырма синтаксисы»нда исә иярченле кушма җөмлә традицион рәвештә аналитик һәм синтетик төрләргә бүлеп бирелә.

Безнең карашка, төрки телләрнең синтаксик төзелешенең үзенчәлеге булган, баш җөмләгә хәбәре формасын тәшкил итүче чара ярдәмендә ияртүле бәйләнеш белән береккән җөмләләрне, рус теле белән чагыштырма тикшеренүләрне җиңеләйтү өчен генә синтетик иярчен җөмлә дип атау максатка ярашлы түгел.

Моннан тыш, татар телендә баш өлешнең (баш җөмлә дип атап булмый, чөнки җөмләнең ике хәбәрлек үзәге булса да, алар аерым-аерым мәгънә белдерми) субъекты позициясендә килгән иярчен җөмләләр дә очрый, рус телендә алар *суперспаянные предложения* (татар телендә термин юк) дип бирелә. Мондый конструкцияләрдә баш өлеш береккән өлештән башка җөмлә дип санала алмый, бәйләүче чара – мәҗбүри янәшә тору һәм ияртүче сүздән пауза белән аерылмау булганлыктан, кушма җөмлә компонентларының чикләрен билгеләү кыенлык тудыра. Мәсәлән: *Һәр ялтыраган алтын түгел* (Мәкаль).

Бу очракта кушма җөмлә компонентлары аерым, бер-берсеннән башка мәгънә белдерми. *Һәр ялтыраган* дигән өлеш формаль яктан үз предикатив үзәге булганга гына җөмлә дип санала: *һәр* – ия, *ялтыраган* – хәбәр. Моннан тыш, *һәр ялтыраган* өлеше үзе субъект позициясендә килә, баш өлешнең хәбәре (*алтын түгел)* ияннән башка үзе генә тәмамланган уйны белдерми.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, төрки телләрдә аналитик ияртүле бәйләнешле конструкцияләрне генә иярченле кушма җөмлә дип атау дөресрәк. Кабул ителгән терминология буенча синтетик иярчен җөмлә дип өйрәнелгән конструкцияләрнең татарча атамасы төгәлләштерүне таләп итә. М.З. Зәкиев «Татар грамматикасы»нда вариант буларак телгә алган *берекмә җөмлә* термины бу очракта уңышлырак дип саныйбыз.

**Әдәбият**

1. *Адмони В.Г.* Сложноспаянное предложение в тюркских языках // Советская тюркология. 1982. № 3. С. 30–36.

2. *Алпаров Г.Х.* Шәкли нигездә татар грамматикасы (Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә). Казан: Татгосиздат, 1926. 164 б.

3. *Байрамова Л.К., Сафиуллина Ф.С.* Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1989. 197 с.

4. *Вәлиди Җ.* Татар теленең грамматикасы. Казан: Миллият, 1919. 175 б.

5. *Дубровина М.Э.* Отсутствие тюркских сложноподчиненных предложений как следствие внутреннего устройства агглютинативных языков // Вестник Российского университета дружбы народов. Серия: Теория языка. Семиотика. Семантика. 2017. Т. 8. № 3. С. 563–570.

6. *Ефремов Н.Н.* Аналитические сложноподчиненные предложения в якутском языке (в сопоставлении с хакасским языком) // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2013. № 11 (29). Часть 1. С. 66–69.

7. *Закиев М.З.* Актуальные проблемы сложных предложений в тюркских языках // Советская тюркология. 1983. № 3. С. 29–38.

8. *Закиев М.З.* Татарская грамматика. Т. III. Синтаксис. Казань, 1995. 576 с.

9. *Ибраһимов Г.* Татар нәхүе. Казан: Өмет, 1919. 52 б.

10. *Ибраһимов С.М.* Татар телендә аналитик төзелмәләр. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1964. 134 б.

11. *Иванова А.М.* Послелоги как средство связи частей сложноподчиненного предложения в чувашском языке // Вестник Томского государственного педагогического университета (Tomsk State Pedagogical University Bulletin). 2011. Вып. 9 (111). С. 168–172.

12. *Козуев Д.И.* Структурно-семантическое сопоставление английских и кыргызских бессоюзных сложных предложений // Вестник КРСУ. 2019. Т. 19. № 6. С. 59–67.

13. *Мусаев С.Ж.* Основные способы связи компонентов сложноподчиненного предложения в кыргызском языке // Turkologia. 2019. № 1 (93). С. 11–25.

14. Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. Казань: ИЯЛИ, 2016. 248 с.

15. *Саидов А.М.* Предикативные слова как сказуемые спаянных частей сложноспаянных предложений в кумыкском языке // Вестник Института языка, литературы и искусства им. Г. Цадасы ДФИЦ РАН. 2021. № 25. С. 16–18.

16. *Самситова Л.Х., Сагынбек И.Ж.* История изучения сложноподчиненных предложений в казахском языке // Проблемы востоковедения. 2024. № 4 (106). С. 91–98.

17. *Самситова Л.Х., Сагынбек И.Ж.* Теоретические основы изучения сложноподчиненного предложения в башкирском языке // Проблемы востоковедения. 2022. № 4 (98). С. 40–46.

18. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм авт. М.З. Зәкиев. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. III. 536 б.

***Хәбибуллина Лениза Газинур кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Хабибуллина Лениза Газинуровна,***
*доктор филологических наук, старший научный сотрудник отдела ареальной лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*valievalg@mail.ru*